ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422176

Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

22 ноябрь 2018 ел №20

## 2018 елның 18 ноябре референдум карарын тормышка ашыру максатларында чаралар планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 901 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында ", Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды:

1. «2018 елның 18 ноябрендә кабул ителгән референдум карарын тормышка ашыру максатларында чаралар планын расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга mamadysh.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштырырга (pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Албай авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: /И.П.Крешков/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 22 ноябре карарына
Кушымта 1

**2018 елның 18 ноябрендәге**
**җирле референдум карарын тормышка ашыру максатларында**
**чаралар планы**

| № п/п | Чаралар | үтәлеш вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Үзара салым түләү өчен авыл жирлеге гражданнарының исемлеген әзерләү | 3 декабрьгә кадәр | Авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 2. | Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү тәртибе турында хәбәр итү | 10 декабрьгә кадәр | Авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3. | Үзара салым акчаларын җыю | 2019 елның 28 февраленә кадәр | Авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 4. | Гражданнарның үзара салым акчаларын исәпләү, тулы күләмдә һәм вакытында түләү дөреслеген контрольдә тоту | даими | Авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 5. | Бирелгән мәгълүматлар буенча үзара салым буенча недоимка торышы анализы үткәрү | даими рәвештә | Авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 6. | 2018 елның 18 ноябре Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларга чыгымнар сметасын раслау | 2019 елның 15 апреленә кадәр | Авыл җирлеге Башкарма комитеты, Мамадыш районы Башкарма комитетының финанс – бюджет палатасы |
| 7. | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның | агымдагы финанс елының I кварталы тәмамланганнан соң 15 календарь көн эчендә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 1 нче кушымтасы нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү өчен гариза бирү | | |
| 8. | Акчаларны максатчан файдалануны контрольдә тоту | Ел дәвамында | ТР Мамадыш муниципаль районының Контроль – хисап палатасы муниципаль казна учреждениеse |
| 9. | Авыл җирлеге башлыгынын Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларның үтәлеше турында отчеты | Елга бер тапкыр | Авыл җирлеге башлыгы |
| 10. | Авыл җирлеге башлыгынын Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларның үтәлеше турындагы отчетын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм (яки) Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итү mamadysh.tatarstan.ru. | 5 көн эчендә | Авыл җирлеге башлыгы |